РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башкарма комитеты

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«18» апрель, 2025 ел**

**КАРАР**
**№ 36**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа турында»18.01.2023 №1 карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүне вакытыннан алда өзү турында 2025 елның 10 гыйнварындагы килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа турында»18.01.2023 №1 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет «мәгълүмат-коммуникацион челтәре»ндә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р.К.Галимҗанова